**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

03.07.2023 № 221

**Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерү проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча координация советы төзү турында**

Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерүне яңадан башлап җибәрү эшен оештыру максатларында:

1. Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерү проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча координация советы төзергә.

2. Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерү проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча координация советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «03» июлендәге
221 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерү проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча координация советы турында**
**нигезләмә**

1. Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерү проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча координация советы (алга таба – Координация советы) кремний органик материаллар җитештерү проектын (алга таба – проект) гамәлгә ашыруны контрольдә тоту һәм тәэмин итү максатларында төзелде.

2. Координация советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Координация советы түбәндәге мәсьәләләр буенча проектны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны башкара:

проект һәм эш документларын эшләү;

җиһазларның сәнәгать куркынычсызлыгына экспертиза үткәрү;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле объектлар төзүнең бәясен исәпләү;

энергия чыганакларына тоташтыру;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле объектлар төзүгә рөхсәт документларын алу;

төзелеш-монтаж эшләре һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләре;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле объектларны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт документлары алу.

4. Координация советы үз эшчәнлеген утырышлар рәвешендә алып бара. Координация советы утырышлары айга бер тапкыр турыдан-туры катнашу форматында яки видео-конференц-элемтә режимында уздырыла. Утырышларны читтән торып катнашу форматында уздыру рөхсәт ителми.

5. Координация советы составына анык эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша торган Координация советы җитәкчесе, Координация советы җитәкчесе урынбасарлары, Координация советы секретаре, Координация советы әгъзалары керә.

6. Координация советы утырышларын Координация советы җитәкчесе, ә ул булмаганда Координация советы җитәкчесе кушуы буенча Координация советы җитәкчесе урынбасарларының берсе уздыра.

Координация советы җитәкчесе:

Координация советы эшенә җитәкчелек итә;

Координация советы утырышларын уздыру тәкъдиме белән чыга һәм аларны уздыра;

Координация советы эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләрне Координация советына фикер алышуга тәкъдим итә;

кирәк булганда Координация советы җитәкчесе урынбасарына вәкаләтләр бирә.

7. Координация советы утырышларын уздыру һәм оештыру Координация советы секретарена йөкләнә.

Координация советы секретаре:

утырышны уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Координация советы әгъзаларына утырышларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында язма рәвештә хәбәр итә;

утырышны уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Координация советы әгъзаларына утырышның көн тәртибен һәм башка материалларны юллый;

Координация советы утырышлары беркетмәләре проектларын һәм беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм аларны Координация советы әгъзаларына юллый.

8. Координация советы утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы, утырышта рәислек итүчене дә кертеп, катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

9. Координация советы утырышына проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшергәндә башка затлар (оешмалар вәкилләре) чакырылырга мөмкин.

10. Координация советы карарлары утырышта катнашучы Координация советы әгъзаларының күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

11. Координация советы карары беркетмә буларак рәсмиләштерелә, аның утырышта рәислек итүченең имзасы куелган проекты Координация советы секретаре тарафыннан утырыш уздырылганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Координация советы әгъзаларына таратыла.

12. Координация советы әгъзалары беркетмә проектын килештерә яисә беркетмә проектын алган көннән ике эш көне дәвамында үз искәрмәләрен Координация советы секретарена тәкъдим итә. Әлеге вакыт тәмамланганнан соң, беркетмә проекты Координация советы әгъзалары белән килештерелгән дип санала.

13. Килештерелгәннән соң беркетмә проекты Координация советы җитәкчесенә, ә ул булмаганда – Координация советы җитәкчесе урынбасарына раслауга тапшырыла.

14. Координация советы карарлары аларның вәкилләре Координация советы составына кертелгән Татарстан Республикасында гавами хакимият бердәм системасына кергән органнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

15. Координация советы карарларының үтәлешен Координация советы секретаре контрольдә тота.

16. Координация советын матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «03» июлендәге
221 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Казан синтетик каучук заводы мәйданчыгында кремний органик материаллар җитештерү проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы составы**

| | |
|---|---|
| Коробченко<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Координация советы җитәкчесе |
| Нигъмәтҗанов<br>Азат Роберт улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте буенча беренче урынбасары, Координация советы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Юрин<br>Михаил Николаевич | Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, Координация советы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Минсадыйров<br>Ирек Илдар улы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының химия һәм газ химиясе бүлеге башлыгы, Координация советы секретаре |
| Әгълиуллин<br>Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Галиев<br>Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Гатин<br>Айрат Дамир улы | «Полибиохим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зверев<br>Олег Игоревич | «Татэнерго» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – җәмгыятьнең җылылык һәм электр энергиясен сату буенча директоры (килешү буенча) |
| Казаков<br>Юрий Михайлович | «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Клиенков<br>Владислав Иванович | «Силикон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Кочнев<br>Павел Владимирович | «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Союзхимпромпроект» проект институты директоры (килешү буенча) |
| Латыйпов<br>Альмир Гамир улы | «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – җәмгыятьнең техник директоры (килешү буенча) |
| Миңнебаев<br>Марат Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Мөбарәкшин<br>Азат Фәрит улы | Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Новиков<br>Роман Олегович | Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе директорының предприятиене үстерү буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Самилов<br>Валерий Иванович | «Полибиохим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Смирнов Артур Владимирович | Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Химия-технология комплексы һәм биоинженерлык технологияләре департаменты директоры (килешү буенча) |
| Тишкин Василий Сергеевич | «Дәүләт экспертизасы баш идарәсе» федераль автоном учреждениесенең Идел буе филиалы башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |